КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 июль г.Казань № 553

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен һәм техник тикшерү талоны дубликатын рәсмиләштергән өчен чыгымнарның иң чик күләмен билгеләү турында» 2011 ел, 27 декабрь, 1079 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен һәм техник тикшерү талоны дубликатын рәсмиләштергән өчен чыгымнарның иң чик күләмен билгеләү турында» 2011 ел, 27 декабрь, 1079 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәрен билгеләү турында»;

1 нче пунктта «һәм техник тикшерү талоны дубликатын рәсмиләштергән өчен чыгымнарның иң чик күләмен» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карарга теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 27 декабрь, 1079 нчы
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 4 июль, 553 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында
транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен
түләүнең иң чик күләмнәре

| Т/с | Транспорт чарасы категориясе* | Транспорт чарасы тибы | Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | $M_1$ | Пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган һәм автомобильләр йөртүче урыныннан тыш утыру өчен иң күбе сигез урыны булган транспорт чаралары | 400,0 |
| 2. | $M_2$ | Пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган, автомобильләр йөртүче урыныннан тыш утыру өчен иң күбе сигездән артык урыны булган, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 5 тоннадан артмаган транспорт чаралары | 630,0 |
| 3. | $M_3$ | Пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган, автомобильләр йөртүче урыныннан тыш утыру өчен иң күбе сигездән артык урыны булган, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 5 тоннадан арткан транспорт чаралары | 740,0 |
| 4. | $N_1$ | Йөкләр ташу өчен билгеләнгән, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы иң күбе 3,5 тонна булган транспорт чаралары | 420,0 |
| 5. | $N_2$ | Йөкләр ташу өчен билгеләнгән, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 3,5 тоннадан арткан, ләкин 12 тоннадан кимрәк булган транспорт чаралары | 720,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | $N_3$ | Йөкләр ташу өчен билгеләнгән, техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 12 тоннадан арткан транспорт чаралары | 770,0 |
| 7. | $O_1$, $O_2$ | Техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы иң күбе 3,5 тонна булган тагылмалар | 350,0 |
| 8. | $O_3$, $O_4$ | Техник яктан рөхсәт ителә торган максималь массасы 3,5 тоннадан арткан тагылмалар | 530,0 |
| 9. | L | Мототранспорт чаралары | 200,0 |

<*> Транспорт чарасын тиешле категориягә кертү Таможня берлеге комиссиясенең «Таможня берлегенең «Көпчәкле транспорт чаралары иминлеге турында»гы техник регламентын кабул итү хакында» 2011 ел, 9 декабрь, 877 нче карары белән кабул ителгән Таможня берлегенең «Көпчәкле транспорт чаралары иминлеге турында»гы техник регламентына теркәлгән 1 нче кушымтада билгеләнгән классификация буенча башкарыла.

________________________________